Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XVII - 1**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 15 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының 2016 елгы социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2017 елга бурычлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 11.1 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 маддәсендәге 9.1 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсендәге 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы И.Г.Вәлиевның 2016 елгы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2017 елга бурычлары турында хисабын игътибарга алырга.

2.Тәкъдим итәргә:

2.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына:

-2017 елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы докладында билгеләнгән искәртүләрне бетерү һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләргә;

- «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе»үтәлешен тәэмин итәргә;

- районда икътисад һәм социаль өлкә секторлары үсешен тәэмин итәргә, инвестицион мәйданчыкларны үстерү һәм гамәлдәге инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен чаралар күрергә;

-торак төзелеше, шул исәптән индивидуаль торак төзелеше темпларын саклап калырга;

- районның инфраструктур үсеше (юллар челтәрен үстерү, объектлар төзү, торак-коммуналь хуҗалык объектлары эшләве) буенча эшне дәвам итәргә;

- «2015-2017 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау " һәм "2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хокук

бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру" муниципаль программаларының үтәлешенә аерым игътибар бирергә;

-торак, клублар, фельдшер - акушерлык пунктлары, спорт учреждениеләре, күпфатирлы йортларга капиталь ремонт, белем бирү оешмаларын, газлаштыру, су һәм электр белән тәэмин итү һәм юлларны төзекләндерү программаларын сыйфатлы тормышка ашыруны тәэмин итәргә;

2.2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә:

- мәгариф тармагын үстерүгә грант ярдәме конкурсларында актив катнашырга;

- барлык чыгарылыш сыйныф укучыларының да бердәм дәүләт имтиханнары буенча минималь балл бусагасын үтүне тәэмин итәргә;

- барлык фәннәрдән дә укыту сыйфатын күтәрү эшен дәвам итәргә;

- барлык чыгымнарны оптимальләштерү буенча чаралар күрергә;

2.3. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге»муниципаль казна учреждениесенә:

- максималь йөкләүне тәэмин итүгә һәм булган спорт базасын нәтиҗәле куллануга игътибар итәргә;

- балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре һәм оешмаларының эшен активлаштырырга;

- физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнүче халыкның санын арттырырга;

- Татарстан Республикасының туризм буенча дәүләт комитеты белән берлектә «2014-2018 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында туризм үсеше" муниципаль программасын гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә;

- вакыйга туризмын үстерү өчен чаралар күрергә;

2.4. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә:

- муниципаль район территориясендә яшәүче халыкларның телләрен, йолаларын һәм гореф-гадәтләрен саклау өчен шартлар тудыруны тәэмин итәргә;

- район үзешчән коллективларының һөнәри осталык дәрәҗәсен күтәрү өстендә эшне дәвам итәргә, аларны чараларда актив катнашуны тәэмин итәргә;

- мәдәният тармагын үстерү өчен грант ярдәме конкурсларында актив катнашырга, шул исәптән матди-техник базаны ныгытырга;

- социаль-мәдәни өлкә объектларының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итргә;

- районның тарихи-мәдәни мирасын саклау һәм торгызу эшен дәвам итәргә, этникара һәм конфессияара тынычлык һәм татулык өчен шартлар тудырырга һәм ярдәм итәргә;

2.5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә:

-бизнес үсеше өчен оптималь шартлар тудыруны тәэмин итәргә, аерым алганда, районның сәнәгать мәйданчыкларында эшләү өчен күбрәк предприятие-резидентларны җәлеп итәргә;

- гамәлдәге сәнәгать предприятиесе базасында «Русский Мрамор агросәнәгать комплексы» ябык акционерлык җәмгыяте сәнәгать мәйданчыгын төзү буенча эшне дәвам итәргә;

- район территориясендә "Биш җил" туристик кластерын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

- шәхси эшмәкәрлекне үстерүгә игътибар итәргә;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән берлектә районның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, керемнәрне легальләштерү һәм җирле бюджетка салым түләүне контрольдә тоту буенча ведомствоара комиссиясенең, хезмәт базарында кризиска каршы чараларны оештыру һәм контрольдә тоту буенча штабның нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итәргә;

- район җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең иң яхшы күрсәткечләренә ирешү максатыннан индикатив идарә күрсәткечләрен үтәү буенча эшне дәвам итәргә;

2.6.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының финанс-бюджет палатасына:

- билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә социаль әһәмиятле, беренче чираттагы чыгымнар буенча гына чыгымнарны түләүне башкарырга;

- бюджет законнарын үтәп, консолидацияләнгән бюджетның сыйфатлы үтәлешен тәэмин итәргә;

- чыгымнарны оптимальләштерү буенча тиешле чаралар күрергә;

- район бюджетына һәм бюджеттан тыш фондларга төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләрдән, оешмалардан, учреждениеләрдән салым түләүләренең һәм җыемнарның үз вакытында керүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- хезмәт хакын вакытында түләүне һәм район бюджет учреждениеләренә коммуналь хезмәтләр өчен түләүне тәэмин итәргә;

2.7.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасына:

- бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшереп тору эшен дәвам итәргә;

- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә аудит үткәрү эшен дәвам итәргә;

- компетенция чикләрендә муниципаль унитар предприятиеләр эшчәнлегенә финанс контролен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

2.8.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына:

- дәүләт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән файдалануның нәтиҗәлелеген, шулай ук муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен арендага бирү нәтиҗәлелеген күтәрергә;

- максатчан билгеләнештәге җир кишәрлекләреннән файдалануга муниципаль җир контролен тормышка ашыру, шулай ук бу ресурсларның

югары табышлылыгын тәэмин итеп, муниципаль милектән нәтиҗәле файдалануны тикшереп тору эшен активлаштырырга;

- күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бушлай бирү буенча эшне дәвам итәргә;

- район бюджетын тулыландыру максатыннан күчемсез милекне сату буенча эшне дәвам итәргә;

- күчемсез милек объектлары астындагы җир кишәрлекләренә хокукларны үз вакытында рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

- җир кишәрлекләре бүлеп биргәндә җир законнары таләпләрен үтәргә;

2.9. район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына:

- электрон рәвештә күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр санын арттырырга;

- авыл җирлекләре территориясендә кече һәм урта бизнес, гаилә фермалары һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар үсешенә ярдәм итәргә;

- - табигый ресурсларны сакчыл һәм законлы файдалану буенча эшне көчәйтергә (аларның сакланышын һәм арттырылуын тәэмин итәргә);

- булган гидротехник корылмаларны теркәүне тәмамларга;

-торак төзелешен эксплуатацияләүгә әзер (эксплуатацияләнә торган), хокуклары теркәлмәгән торак төзелеше объектларын ачыклау һәм аларны федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәүне тәэмин итү эшен активлаштырырга;

- халыкның тормыш дәрәҗәсен киметмәү һәм гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүләрдән тигез файдалануын тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- җирле үзидарәне тормышка ашыруда һәм территорияләр белән идарә итүдә, шул исәптән иҗтимагый оешмалар эше аша халыкны җәлеп итү эшен көчәйтергә;

- торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә;

- җирлекләр территориясендә законлылык һәм хокук тәртибен саклауны тәэмин итәргә;

- җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан үз вазыйфаларын башкарганда коррупция хәвефләрен бетерүне тәэмин итәргә;

2.10. Балык Бистәсе муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тәкъдим итәргә:

- федераль һәм республика максатчан программаларында катнашу аша авыл хуҗалыгы предприятиеләренең матди базасын ныгыту, терлекләрнең баш санын арттыру буенча чаралар күрергә;

- конкуренциягә сәләтле авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмен арттыру, җирләрдән нәтиҗәле файдалану, җитештерү рентабельлеген арттыру, терлекләрнең баш санын саклап калу, аларны азык белән тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән берлектә халыкның эшлекле активлыгын арттыруга, гаилә фермаларын

үстерүгә, кулланучылар кооперативларын торгызу буенча чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән даими нигездә эш алып барырга;

2.11. барлык милек рәвешләрендәге предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә:

- яңа эш урыннары булдыру, хезмәт хакын тоткарлауны булдырмау, аны арттыру, конкурентлыкка сәләтле сәнәгать продукциясен җитештерү үсешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- район бюджетына салымнарны һәм бюджеттан тыш фондларга түләүләрне вакытында түләүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев